**ГЛАВА**
**Азевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерже муниципаль районы**
**Азево авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

03.10.2022

Азево

№ 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ташлы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Азево авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Азево авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е**:**

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ташлы торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 14 октябрендә 13 сәг 00 мин билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ташлы торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Ташлы авылы урамнарын кардан чистарту.
- Ташлы авылында чүп чабу.
- Ташлы авылының Нагорная, Шкетан урамнарындагы юлларны төзекләндерү өчен вак таш сатып алу.
- Ташлы авылына су алу колонкаларын урнаштыру өчен материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы Ташлы ав., Шкетан урамы, 6, авыл клубында уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы В.С.СЕМЕНОВ

ОГРН 1021600515530 Совет Азёвского сельского поселения Азёво авыл җирлеге Советы ИНН 1601002660 АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ